Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы торак пунктында гражданнар җыены

# КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче Чуаш Ялтаны авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 18 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде «Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү, киртәләр төзү (мөселман зираты коймасын ремонтлау)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларга таш салу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 221 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 136 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 136 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны танырга: «Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү, киртәләр төзү (мөселман зираты коймасын ремонтлау)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларга таш салу).

3. Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең Чуаш Ялтаны авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү, киртәләр төзү (мөселман зираты коймасын ремонтлау)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларга таш салу).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыела торган урыннарына, стендларга һәм такталарга белдерүләр элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге башлыгы ________________ С.М. Егоров